Пыжмара гомуми урта белем мәктәбе

# Тыл хезмәтчәннәре белән очрашу кичәсе

Төзеде: 1 нче категорияле татар теле
һәм әдәбияты укытучысы,
сыйныф җитәкчесе
Латыйпова Р.Г.

# 9 Май – Җиңү Көне уңаеннан авылыбызның тыл хезмәтчәннәре белән очрашу кичәсе

*Егетләр "Герман көе"н башкара*

Сезгә, апалар, сугыш елларында

Теңкәгезгә тиде авырлык.

Заман авырлыгын күтәрергә,

Зур кайгылар баштан кичерергә

Кайдан алдыгыз сез сабырлык?!

Сезнең сабырлыкка, батырлыкка

Мәңге-мәңге хәйран калырлык!

Алып баручы: – Исәнмесез, хөрмәтле тыл ветераннары, укытучылар, укучылар! 9 Май көнне безнең илебез Бөек Җиңүнең 64 еллыгын билгеләп үтәчәк. Шул уңайдан без бүген мәктәбебезгә авылыбызның хөрмәтле кешеләрен – тыл хезмәтчәннәрен чакырдык. Кызганычка каршы, авылыбызда Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан бер Галиев Фәсхетдин абый гына исән инде. Ләкин ул да авырту сәбәпле инде ничә еллар урынныннан тора алмый. Фәсхетдин абыйны якынлашып килүче бәйрәм белән котлап, авыруына җиңеллек телик, аны тәрбия кылучыларга олы рәхмәтебезне белдерик. Моннан бер 10 – 15 еллар элек сугыш һәм тыл ветераннарыбыз безнең һәйкәлебез каршысына сыймылар иде... Еллар узып, үзләре белән ветераннарны да алып киттеләр. Ләкин беркем дә, бернәрсә дә онытылмаган! Аларның тиңсез батырлыгы һәрчак безнең күңелебез түрендә булачак. Чөнки үткәнен оныткан халыкның киләчәге юк һәм була да алмый!

Тиңе булмаган бу дәһшәтле сугыш 1418 көн һәм төн дәвам итте. Күпме балалар әти-әнисез, күпме ата-аналар улларсыз-кызларсыз, күпме хатыннар ирсез, ирләр хатынсыз калдылар! Бу канкойгыч сугыш авылыбызның бер генә йортын да урап узмады.

Бөек Җиңү көнен сугыш кырында батыр солдатлар якынайтса, авылларда, шәһәрләрдә аны якынайтыр өчен тыл хезмәтчәннәре җан көчләрен куеп тырыштылар. Фронтка, сугышка дип үзләре ач-ялангач калган, ул әйтеп бетергесез авыр елларда бер телем ипигә тилмергән,иске бишмәт, күтәртмәле чабата киеп, черек бәрәңге ашап, салам ягып өй җылытып, үгез белән сука

тартып, аркылы пычкы белән урман кисеп, ләкин шуңа да карамастан, ачлыкка, сугыш, югалту ачысына бирешмәгән, күңелләре белән көр калган тыл батырлары безнең каршыбызда бүген. Сезгә, хөрмәтле ветераннар, безгә шушындый якты, ямьле тормыш яулап биргәнегез өчен мең-мең рәхмәт! Без алдыгызда башыбызны иябез!

Әйдәгез, аларны сәхнәбез түренә чакырыйк һәм сүзне аларга бирик.

Менә алар безнең хөрмәтле кешеләребез: Сабирова Әминә апа, Хабибуллина Файза апа, Фазылова Фәхриямал апа, Гайнанова Зөлфия апа.

Хөрмәтле ак аулыклы апаларыбыз! Сезнең гүзәл яшьлегегез ачы сугыш елларына туры килде. Ул еллардагы гыйбрәтле вакыйгалар, үзегезнең авыр хезмәтегез турында безгә дә сөйләгез әле.

***(Апаларның һәрберсенә сүз бирелә)***

Әминә апа:

Зөлфия апа:

Файза апа:

Фәхриямал апа:

Алып баручы: - Кешенең бу тормышта якты эзе, матур эше калырга тиеш. Сезнең буынның үткәнен безгә үрнәк итеп куярлык!

Рәхмәт Сезгә!

Чәчләрегез агарса да,

Авыр еллар маңгайларга

Тирән эз салса да,

Тормыш Сезне утка-суга

Салып сынаса да

Саф намуска хыянәтсез калган өчен

Рәхмәт Сезгә!

Рөстәм Ахметханов башкаруында “Кирәкми сугыш” җыры.